Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

# Б О Е Р Ы К

Казан ш.

12.03.2015 №37/2-пр

“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “2012 елның 28 февралендәге 165 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын гамәлгә ашыру турында” 2012 елның 22 мартындагы 198 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы арасында төзелә торган 2015 елның 5 февралендәге 48/17-с номерлы Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында килешүгә нигезләнеп,

**б о е р ы к  б и р ә м:**

1. “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү өчен крестьян (фермер) хуҗалыклары проектларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составын 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү өчен крестьян (фермер) хуҗалыклары проектларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе каршындагы экспертлар советы составын 4 нче кушымта нигезендә расларга.
5. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) муниципаль районнардагы Авыл-хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын мәгълүмат белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтергә.

6. Министрлыкның финанс бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмәдә каралган билгеләнгән лимитлар чикләрендә акчаларны үз вакытында җиткерүне тәэмин итәргә.

7. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

12.03.2015 елның 37/2-4 номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

# “2015 - 2017 елларга ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КРЕСТЬЯН (ФЕРМЕР) ХУҖАЛЫКЛАРЫ БАЗАСЫНДА ГАИЛӘ ТЕРЛЕКЧЕЛЕК ФЕРМАЛАРЫН ҮСТЕРҮ”

# ВЕДОМСТВО ПРОГРАММАСЫ

**Казан – 2015**

## Эчтәлек

Программа паспорты 3

1 бүлек Проблемага характеристика һәм аны хәл итү зарурлыгы 5

2 бүлек Программаның максатлары һәм бурычлары 6

3 бүлек Кирәкле ресурсларга ихтыяҗларны нигезләү 7

4 бүлек Көтелгән нәтиҗәләр һәм максатчан күрсәткечләр 7

5 бүлек Программа чараларының исеме һәм тасвирламасы 8

6 бүлек Программаны гамәлгә ашыру сроклары 11

7 бүлек Программа чараларын гамәлгә ашыруның социаль һәм икътисадый нәтиҗәләренә фараз 11

8 бүлек Программа нәтиҗәлелеген бәяләү 12

9 бүлек Программаны гамәлгә ашыруга идарә итү системасы 13

1 нче кушымта 14

2 нче кушымтам 15

# ПАСПОРТ

| | |
|---|---|
| Программа исеме | “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасы (алга таба – Программа) |
| Программа эшләү турында карар кабул итү датасы (аны раслау датасы, тиешле норматив актның датасы һәм номеры) | “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында” 2015 елның 12 мартындагы 37/2-пр номерлы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгы |
| Программаның дәүләт заказчысы-координаторы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) |
| Программаның максаты һәм бурычлары | Программа максаты:<br>Авыл халкы тормышын яхшырту.<br>Программа бурычлары:<br>1. Крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында заманча югары технологияле гаилә терлекчелек фермаларыы санын арттыру, аларны алга таба үстерү һәм Татарстан Республикасы территориясендә җәелдерү;<br>2. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыру, авыл халкын үз шөгыльләре белән тәэмин итү һәм даими өстәмә эш урыннары булдыру;<br>3. Терлек һәм кошларның төрле төрләре баш исәбен арттыру |

| | |
|---|---|
| Программа гамәлләренә характеристика | Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән чаралар комплексы үз эченә түбәндәгеләрне ала:<br>1. Гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүнең проект документларын эшләү;<br>2. Гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү;<br>3. Терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү;<br>4. Гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча объектларны җиһазлар һәм техника белән җиһазлау, шулай ук аларны монтажлау;<br>5. Авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алу |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2015 ел – 40 гаилә фермасын, 120 эш урынын булдыру;<br>2016 ел – 42 гаилә фермасын, 126 эш урынын булдыру;<br>2017 ел – 44 гаилә фермасын, 132 эш урынын булдыру |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Гаилә терлекчелек фермаларын төзүне гамәлгә ашыруга чыгымнар күләме барлыгы 613,614 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2015 елда – 204,538 млн. сум;<br>2016 елда – 204,538 млн. сум;<br>2017 елда – 204,538 млн. сум;<br>федераль бюджеттан – 68,169 млн. сум,<br>шулардан еллар буенча:<br>2015 елда – 22,723 млн. сум;<br>2016 елда – 22,723 млн. сум;<br>2017 елда – 22,723 млн. сум;<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан – 300 млн. сум,<br>шулардан еллар буенча:<br>2015 елда – 100 млн. сум;<br>2016 елда – 100 млн. сум;<br>2017 елда – 100 млн. сум;<br>җәлеп ителгән акчалар – 245,445 млн. сум,<br>шулардан еллар буенча:<br>2015 елда – 81,815 млн. сум;<br>2016 елда – 81,815 млн. сум;<br>2017 елда – 81,815 млн. сум. |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәчәк:<br>КФХ базасында гаилә терлекчелек фермаларының 126 берәмлеккә артуын;<br>сөт җитештерү күләмнәренең елына 2,3 мең тоннага артуын;<br>ит җитештерү күләмнәренең елына 374 тоннага артуын;<br>Программаны гамәлгә ашыру чорында сыерларның баш исәбе 528 башка артуны;<br>булдырылган эш урыннары санының 378 дән ким булмавын. |

## Программаның төп төшенчәләре

**Гаилә терлекчелек фермасы** - авыл хуҗалыгы терлеген үрчетү һәм асрау өчен билгеләнгән, крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба – КФХ) милкендәге яки файдалануындагы җитештерү объекты;

**гаилә терлекчелек фермасын үстерү** - гаилә терлекчелек фермасын төзү яки модернизацияләү, шул исәптән аны проектлау, салу, ремонтлау, җиһазлар һәм авыл хуҗалыгы терлеге белән комплектлау;

**гаилә терлекчелек фермасын үстерүгә грант –** Программа нигезендә дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында капланмый торган чыгымнарны финанслашу өчен кредит оешмасында ачылган КФХ башлыгы счетына Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территориясендә һәм авылара территорияләрдә КФХ төзү һәм үстерү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан яки җирле бюджеттан күчерелә торган акчалар, шул исәптән түбәндәгеләр өчен:

гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүнең проект документларын эшләүгә;

гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүгә;

терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүгә;

гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча объектларны җиһазлар һәм техника белән җиһазлауга, шулай ук аларны монтажлауга;

авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алуга.

## 1 бүлек. Проблемага характеристика һәм аны хәл итү зарурлыгы

Соңгы унъеллыкларда авыл халкы саны кимү динамикасы сакланып кала, Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенча алар 2014 елда республика халкының

гомуми санынннан 23,9 процент тәшкил итте, чагыштырып карау өчен 1995 елда – 27,1 процент.

“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасы авыл җирендә яшәү өчен кызыктырырлык булуын арттыру, авыл халкының үз-үзенә шөгыль табуын тәэмин итү, авыл яшьләренең эшкә карата булган активлыгын арттыру, авылча яшәү рәвешен саклап калу максатларында эшләнде.

Авыл хуҗалыгы җитештерүендә кадрлар составын ныгыту, кече эшкуарлыкны үстерү һәм яңа эш урыннары булдыру, авыл яшьләренең кызыксынучанлыгын һәм эш белән тәэмин ителүен арттыру максатларында Программада КФХ базасында гаилә терлекчелек фермаларына ярдәм чаралары комплексы тәкъдим ителә.

Халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыклары (алга таба – ЛПХ) секторында кимендә 10 сыеры булган хуҗалыклар барлыкка килде, алар товар продукцияне җитештерүне күз алдында тотып эшлиләр. Алар хәзер үк терлекчелек продукциясе күләме буенча кайбер фермер хуҗалыкларыннан алга киттеләр. Чынлыкта исә гаилә терлекчелек фермалары үзләре кредит, лизинг, эшкәртү һәм башка оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр төзи алу мөмкинлекләре булмаган ЛПХ базасында оеша.

КФХ базасында гаилә терлекчелек фермасын төзегәндә шактый җитди проблемалар барлыкка килә: башлангыч капиталның җитәрлек булмавы, залогка куя торган мөлкәтнең җитәрлек булмавы аркасында алар кредит ала алмыйлар, шулай ук хуҗалык корылмаларын проектлауга, аларны инженерлык челтәрләренә тоташтыруга, лизинг түләүләре буенча башлангыч кертемнәр түләүгә һәм башкаларга зур чыгымнар таләп ителә.

КФХның терлекчелекне үстерүдә билгеле бер потенциалы бар һәм алар эре предприятиеләр эшчәнлеге файда китерми торган яисә бөтенләй мөмкин булмаган базар кырында эшлиләр. Кече предприятиеләр тизрәк яраклаша алалар, капиталның чагыштырмача югары әйләнешен башкаралар. Аларны берләштергәндә якындагы сәүдә нокталарына, гомуми белем бирү учреждениеләренә һәм сәламәтлек саклау учреждениеләренә сату өчен продукцияне зур булмаган күләмнәрдә җитештерә торган эшкәртү пунктын төзү мөмкинлекләре күбрәк була. Мәсәлән, чит илдә сөт эшкәртә торган предприятиеләрнең күбесе кооперативлар рәвешендә төзелгән һәм шуның нәтиҗәсендә фермер керемне сөт тапшырудан алмый, ә эшкәртү производствосы табышыннан ала.

## 2 бүлек. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программа максаты:

авыл халкының яшәү дәрәҗәсен арттыру, шәһәр һәм авыл халкын үзебездә җитештерелгән терлекчелек продукциясе белән тәэмин итү.

Программа бурычлары:

1. КФХ базасында югары технологияле заманча гаилә терлекчелек фермалары санын арттыру, аларны алга таба үстерү һәм Татарстан Республикасы территориясендә җәелдерү;

2. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыру, авыл халкының үзенә шөгыль табуын тәэмин итү һәм өстәмә рәвештә даими эш урыннары булдыру;

3. Төрле төрдәге терлек һәм кошларның баш санын арттыру.

## 3 бүлек. Кирәкле ресурсларга ихтыяҗларны нигезләү

2015 – 2017 елларга программаны гамәлгә ашыруга чыгымнар күләме барлыгы 613,614 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

федераль бюджеттан – 68,169 млн.сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан – 300 млн.сум;

җәлеп ителгән акчалардан – 245,445 млн.сум.

Программаны финанслау агымдагы елга һәм план чорына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетлары турында ел саен кабул ителә торган законнар нигезендә башкарыла.

2015 – 2017 елларда КФХ башлыкларына грантларның гомуми суммасы 368,169 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан 300 млн. сум (1 нче кушымта).

Әлеге Программада каралган барлык чараларны финанслау Программаны гамәлгә ашыруның барлык срогы дәвамында башкарыла.

## 4 бүлек. Көтелгән нәтиҗәләр һәм максат күрсәткечләре

Киләчәктә 126 гаилә терлекчелек фермасы дәүләт ярдәме белән үзләренең КФХ үстерү проектларын гамәлгә ашыра алачак.

Программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

1. Киләчәктә 378 эш урынын булдыру өчен шартлар тудыру (бер КФХга киләчәктә өч эш урыны).

2. Тәэмин итү – сату һәм эшкәртү өлкәләрендә авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү.

3. Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү һәм үзләштерү өчен, шулай ук авыл җирлегендә урнашуның хәзерге системасын саклап калу өчен шартлар тудыру.

4. Гаилә эшкуарлыгына ярдәм итү һәм авыл җирлегендә урнашкан яшәү рәвешен саклап калу рәвешендә социаль нәтиҗә алу.

Программа чараларын гамәлгә ашыруның максат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

үзләренең гаилә терлекчелек фермаларын төзү һәм үстерү проектларын дәүләт ярдәме белән гамәлгә ашырган КФХ саны;

өстәмә рәвештә булдырылган даими эш урыннары саны.

Гаилә фермаларын файдалануга кертү (берәмлек)

| Эшчәнлек юнәлеше | КФХ саны, берәмлек | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2015 | 2016 | 2017 | Өч елга барлыгы |
| сөт җитештерү | 22 | 23 | 24 | **69** |
| мөгезле эре терлекне симертү | 12 | 13 | 14 | **39** |
| сарык фермалары | 3 | 3 | 3 | **9** |
| кошлар үрчетү | 2 | 2 | 2 | **6** |
| ат фермалары | 1 | 1 | 1 | **3** |
| Барлыгы: | **40** | **42** | **44** | **126** |

Терлекнең баш исәбе арту

| Терлек төре | Уртача 1 фермага, баш | Бер елга баш исәбе арту, баш |
|---|---|---|
| сыерлар | 24 | 528 |
| үгезләр | 50 | 600 |
| сарыклар | 150 | 450 |
| кошлар | 4000 | 16 000 |
| атлар | 50 | 50 |

## 5 бүлек. Программа чараларының исеме һәм тасвирламасы

КФХ базасында төзелгән, Программада катнаша торган гаилә терлекчелек фермасы шулай ук республиканың башка программа чараларында катнаша ала, ләкин берүк чыгымнарны төрле дәрәҗәдәге бюджетлар исәбеннән икеләтә финанслау рөхсәт ителми.

Программага комплексы дәүләт ярдәмен тәэмин итү өчен гаилә терлекчелек фермаларына ярдәм итү буенча түбәндәгеләр карала:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасын раслау турында” 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм

авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла торган чаралар:

озак вакытка инвестиция кредитлары бирү, шул исәптән авыл хуҗалыгы кулланучылар кредит кооперативларыннан алынган банк инвестиция кредитларын һәм заемнарын субсидияләү;

гаилә терлекчелек фермалары җитештерә торган авыл хуҗалыгы продукциясен сатуны оештыру;

авыл хуҗалыгы кулланучылар кредит кооперативларыннан алынган кыска вакытлы (2 елга кадәр) банк кредитларын һәм заемнарын субсидияләү.

2. Авыл хуҗалыгы техникасы, җиһазлары һәм терлеге лизинглары буенча кертемнәрнең бер өлешен катлау. Чара “Кече һәм урта эшкуарлыкка, крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, дәүләт ярдәме максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 2014 елның 30 декабрендәге 1605 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтекарары кысаларында җиһазларны лизингка алу шартнамәләре буенча беренче түләүләрне түләүгә максатчан субсидиеләр бирүне үз эченә ала;

3. КФХ башлыклары алган кредитлар һәм заемнар буенча эшкуарлыкка ярдәм фондларыннан (“Татарстан Республикасының Гарантия фонды” коммерциясез оешмасы) йөкләмәләр алу һәм гарантияләр бирү;

4. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 июлендәге 598 номерлы карары белән расланган “2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге план чорына авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасы кысаларында КФХ башлыкларының җитештерү һәм социаль объектларына инженерлык-техник инфраструктурасын төзү һәм ремонтлау;

5. Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә булышлык күрсәтү өчен КФХ башлыклары, әгәр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булсалар, “2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге план чорына авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасы кысаларында гамәлгә ашырыла торган торак шартларын яхшырту программаларына кертеләләр.

6. Гаилә терлекчелек фермаларын үстерергә теләгән гражданнарга Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре (алга таба – Идарә) белгечләре тарафыннан консультация бирү хезмәтләрен күрсәтү.

7. Гаилә терлекчелек фермаларын үстерү инфраструктурасын булдыру өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте агробизнес өлкәсендә авыл хуҗалыгын үстерү буенча Дәүләт программалары һәм төбәк программалары гамәлләрендә КФХ башлыкларының катнашуын тәэмин итә. Җирләрнең булуы турында мәгълүмат һәркем өчен ачык була.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы), “Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында” республика заявкаларына һәм төзелгән Килешүләргә нигезләнеп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның

19 декабрендәге 1421 номерлы карары белән расланган “2013 – 2014 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында” карары белән расланган “2015 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге план чорына крестьян (фермер) хуҗалыкларының гаилә терлекчелек фермаларын үстерү ведомство максатчан программасы кысаларында һәм шартлары буенча финанслаша. Финанслашу “Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 28 февралендәге 165 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә билгеләнгән шартларга ярашлы рәвештә һәм лимитлар кысаларында башкарыла.

Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмә, гариза бирүчеләрне Программада катнашучылар составына кертү турында карар кабул итү тлртибен үз эченә алган КФХ башлыкларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибе, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирүгә крестьян (фермер) хуҗалыклары проектларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составы, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирүгә гаризаларны карау буенча конкурс комиссиясе каршындагы экспертлар советы составы Министрлык боерыгы белән расланалар. Министрлык Программада катнашучыларны сайлап алуга конкурс игълан итә, аны үткәрү тәртибен һәм срокларын билгели.

Сайлап алуда катнашу өчен КФХ башлыгы, Программада катнашучыларга карата куелган таләпләргә туры килүен раслый торган документларны һәм 2 нөсхәдә теркәлгән документларның исемлеген беркетеп, конкурс комиссиясенә гариза бирә. Документларны кабул итү турында тамга салынган бер нөсхә – КФХ башлыгында, икенчесе – конкурс комиссиясе секретарендә кала.

Гаилә терлекчелек фермаларын сайлап алуны Министрлык тарафыннан төзелгән конкурс комиссиясе Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы таләпләренә ярашлы рәвештә гамәлгә ашыра.

Крестьян (фермер) хуҗалыгын үстерүгә грантның максималь күләме Министрлык боерыгы белән раслана. Грант суммасы конкурс комиссиясе тарафыннан КФХ башлыгының үз акчалары, кредит яки проектка кертелгән акчаларның булуын исәпкә алып билгеләнә. Чыгымнар планын, шул исәптән грант бирү суммасы чикләрендә үзгәртү конкурс комиссиясе белән килештерелергә тиеш.

Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар түбәндәге программа чараларын башкаруга тотылырга тиеш:

1. Гаилә терлекчелек фермаларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүнең проект-смета документларын эшләү;

2. Гаилә терлекчелек фермаларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү;

3. Терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү;

4. Гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча объектларны җиһазлар һәм техника белән җиһазлау;

5. Авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алу.

Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантларны тоту расланган чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алуларның һәр исеме буенча 18 ай эчендә КФХ үз акчаларының һәм түбәндәгеләрнең нисбәтен исәпкә алып башкарыла: Россия Федерациясе бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән иң күбе 60 проценты һәм КФХ үз акчалары исәбеннән кимендә 40 проценты. КФХ үз акчалары сыйфатында субсидияләнмәгән кредитларның иң күбе 30 проценты күрсәтелә ала.

Конкурс сайлавын узган Программада катнашучы әлеге Программаның 2 нче кушымтасында каралган форма буенча расланган үрнәктәге сертификат ала.

Министрлык акчаларның Программада катнашучыларга барып җитүен һәм алар тарафыннан максатчан сарыф ителүен тикшереп торуны тәэмин итә. Министрлык гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү гамәлгә ашыруда арадашчы булачак кредит оешмасын билгели.

КФХ башлыгына гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грант аның эшчәнлегенең бөтен чоры дәвамында бер генә тапкыр бирелергә мөмкин.

## 6 бүлек. Программаны гамәлгә ашыру сроклары

Программа 2015 – 2017 елларда гамәлгә ашырыла һәм “2012 – 2014 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында” 2012 елның 17 июлендәге 122/2-пр номерлы Министрлык боерыгы белән расланган “2012 - 2014 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасының дәвамы булып тора.

## 7 бүлек. Программа чараларын гамәлгә ашыруның социаль һәм икътисадый нәтиҗәләренә фараз

Программа чараларын гамәлгә ашыру авыл хуҗалыгы өлкәсендә стратегик максатларга ирешергә, әйтик, авыл хуҗалыгының финанс тотрыклылыгына һәм аны модернизацияләүгә нигезләнеп үзебезнең авыл хуҗалыгы продукциясенең конкуренция тудыра алучанлыгын арттыруга, авыл территорияләрен тотрыклы үстерүгә, авыл халкын эш белән тәэмин итүне һәм аларның тормыш дәрәҗәсен яхшыртуга, сәүдә киштәләрендә үзебезнең терлекчелек продукциясенең өлешен арттыруга ярдәм итәчәк.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә тактик һәм стратегик бурычларның хәл ителеш дәрәҗәсен чагылдыра торган күрсәткечләр КФХ саны арту һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләмнәре арту була.

Программа чараларын гамәлгә ашыру авылда КФХны тотрыклы үстерү өчен алшартлар булдырачак, шул исәптән 2020 елга кадәрге перспективада аларга дәүләт ярдәме тәҗрибәсен һәм механизмнарын шомартачак.

Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә КФХның авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең - елына сөтнең 2,3 мең тоннага һәм итнең 374 тоннага - артуы күздә тотыла.

Шулай ук, Программаның нигезләнгән максатчан күрсәткечләрендә каралганча, гаилә терлекчелек фермаларының саны 126 берәмлеккә артачак. Моннан тыш, бер КФХ өч һәм аннан күбрәк эш урыны белән тәэмин итәчәк, барлыгы 378 эш урыны булдырылачак.

Нәтиҗәдә дәүләт федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан эшсезлек буенча пособиегә түләүләр күләме кимүдән, салым җыемнары артудан өстәмә икътисадый файда алачак.

Программа чараларын гамәлгә ашыру тискәре икътисадый зыян китермиячәк, әмма авыл хуҗалыгы җирләренең сыйфатын яхшырту буенча культура-техника чараларын үткәрү юлы белән табигый ресурсларны саклап калуга ярдәм итәчәк.

Программа чараларын гамәлгә ашыруның беренче уйланылган нәтиҗәләренә йогынты ясарга мөмкин тышкы шартларга һәм куркынычларга түбәндәгеләрне кертеп була:

фиананслауның КФХ һәм терлекчелек продукциясен беренчел эшкәртү цехларының искергән техник базасын физик һәм әчке яктан яңартырга мөмкинлек бирмәячәк түбән дәрәҗәсе;

авыл хуҗалыгы техникасына һәм терлекчелек фермалары өчен каралган җиһазларга, терлекчелек фермаларын төзү өчен кирәкле материалларга бәяләрнең инфляция үсү темплары белән аңлатыла торган көтелгән артуыннан тагы да күбрәккә артуы;

кредитлар буенча процент ставкаларының артуы;

аномаль һава торышы һәм административ үзгәртеп корулар, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының структурасындагы үзгәрешләргә һәм тиешле вәкаләтләрнең Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында яңадан бүленүенә бәйле рәвештә булырга мөмкин институциональ үзгәрешләр аркасында барлыкка килү ихтималы булган форс-мажор шартлар.

Күрсәтелгән куркынычлар форс-мажор булып тора, шулай ук алар Министрлык системасына кермәгән хакимият органнары эшчәнлегенә бәйле, шуңа күрә аларны алдан фаразлау мөмкин түгел.

## 8 бүлек. Программа нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа нәтиҗәлелегенең механизмы:

Программаның КФХ базасында гаилә терлекчелек фермаларын төзү һәм комплектлау буенча чараларының Татарстан Республикасында гамәлгә ашырылуын өйрәнү, тәҗрибәне гомумиләштерү һәм нәтиҗәлелеген бәйләү.

Анализ күрсәткече:

Татарстан Республикасында Программаны гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән гаилә терлекчелек фермалары санын, Программада катнашучыларны конкурс нигезендә сайлап алып, 126 берәмлек терлекчелек фермасына арттыру.

Гаилә терлекчелек фермаларын үстерү буенча республика программаларын гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан финанслашу бирү аларның сарыф ителүенә мониторинг уздыруны таләп итә. Бу максаттан Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы хисап бирү рәвешен һәм аны бирү тәртибен билгели.

Мониторинг уздыру түбәндәгеләрне күз алдында тота:

1. Программада катнашучы КФХ, чынбарлыктагы һәм финанслаша торган чыгымнар, акчаларның нәтиҗәле тотылуы турында мәгълүмат бирү.

2. Әлеге бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат бирүнең ешлыгы һәм форматы.

3. Программа чараларын гамәлгә ашыру кысаларында агымдагы чорга хисап бирүнең яңа формасын эшләү.

## 9 бүлек. Программаны гамәлгә ашыруга идарә итү системасы

Программа чараларын гамәлгә ашыруга оештыру-методика ягыннан идарә итүне дәүләт заказчысы һәм координаторы булып торган Министрлык башкара.

Министрлык программа чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча тармак министрлыклар һәм ведомстволар арасында килештерелгән эшләрне тәэмин итә.

Министрлык түбәндәгеләрне тапшыра:

“Агростат” АПК статистика мәгълүматын автоматлаштырылган рәвештә җыю һәм анализлау системасы өчен Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгына – ярты елга бер тапкыр, хисап яртыеллыгыннан соң килә торган айның 20 нче числосына кадәр, Программа чараларының гамәлгә ашырылуы турында мәгълүматны;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына – ярты елга бер тапкыр, хисап яртыеллыгыннан соң килә торган айның 25 нче числосына кадәр, Программа чараларының гамәлгә ашырылуы турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүматны;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына – билгеләнгән тәртип нигезендә докладлар эчендә Программана гамәлгә ашыру эшләрен башкаруның барышы һәм финанс чараларын тотуның нәтиҗәлелеге турында мәгълүматны.

2015 елның 12.03 37/2-11 номерл
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгы белән расланга
Программага 1 нче кушымта

**Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чаралары буенча финанслау**

| Максатлар | Бурычлар | Төп чаралар | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, исәпләү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | Финанслау, финанслау чыганагын күрсәтеп (млн.сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел |
| Авыл халкы тормышын яхшырту | 126 гаилә терлекчелек фермасын төзү | Гаилә терлекчелек фермаларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү, шулай ук аларны товар терлек, техника һәм җиһазлар белән комплектлау | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2015 – 2017 еллар | Гаилә терлекчелек фермаларының саны арту, берәмлек | 40 | 42 | 44 | Барлыгы – 204,538; шул исәптән 100 - Татарстан Республикасы бюджеты; 22,723 – федераль бюджет; 81,815 – җәлеп ителгән акчалар | Барлыгы – 204,538; шул исәптән 100 - Татарстан Республикасы бюджеты; 22,723 – федераль бюджет; 81,815 – җәлеп ителгән акчалар | Барлыгы – 204,538; шул исәптән 100 - Татарстан Республикасы бюджеты; 22,723 – федераль бюджет; 81,815 – җәлеп ителгән акчалар |
| | | | | | Өстәмә булдырыла торган эш урыннары саны | 120 | 126 | 132 | | | |

2015 елның 12.03 номерлы 37/2-пр
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгы
белән расланган Программага
2 нче кушымта

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

# СЕРТИФИКАТ

***Әлеге сертификат белән***

_______________________________________________

***(фамилиясе, исеме, атасы исеме)***

_______________________________________________

***(сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайда бирелгән)***

***һәм крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәве турында таныклык***_______________________________________

***(ОГРНИП номеры һәм датасы)***

***Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2015 елның 12 мартындагы 37/2-пр номерлы боерыгы белән расланган***
***“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” программасында катнашучы буларак таныклана һәм аңа***
_________________ ***муниципаль районында***
***гаилә терлекчелек фермасын үстерүгә***
_______________________________________________ ***сум күләмендә***

***грант бирелә.***

Бирелү датасы ______________, 2015 ел

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министры М.Г. Әхмәтов

серия 16 №_______, “____” __________, 2015 ел

12.03.2015 № 37/2-пр
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

# Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмәне

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә “2012 елның 28 февралендәге 165 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын гамәлгә ашыру турында” Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2012 елның 22 мартындагы 198 номерлы боерыгы нигезендә һәм “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасына (алга таба – Программа) ярашлы рәвештә әзерләнде.

Әлеге Нигезләмә дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибен, проектларны сайлап алу критерийларын, проектларны конкурс нигезендә сайлап алуның максатларын, шартларын, оештыру процедурасын билгели.

Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр:

**гариза бирүче** – Программада катнашучы дип тану өчен конкурс комиссиясенә гариза бирүче һәм әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килүче крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба – КФХ) башлыгы;

**гаилә терлекчелек фермасы** – авыл хуҗалыгы терлеген үрчетү һәм асрау өчен билгеләнгән, КФХ милкендәге яки файдалануындагы җитештерү объекты;

**гаилә терлекчелек фермасын үстерүгә грант –** Программа нигезендә дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында капланмый торган чыгымнарны финанслашу өчен кредит оешмасында ачылган КФХ башлыгы счетына Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территориясендә һәм авылара территорияләрдә КФХ төзү һәм үстерү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан яки җирле бюджеттан күчерелә торган акчалар, шул исәптән түбәндәгеләр өчен:

гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүнең проект документларын эшләүгә;

гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүгә;

терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүгә;

гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча объектларны җиһазлар һәм техника белән җиһазлауга, шулай ук аларны монтажлауга;

авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алуга (алга таба – грант);

**конкурс комиссиясе** – гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү өчен КФХ проектларын сайлап алу максатларында төзелгән ведомствоара конкурс комиссиясе;

**экспертлар советы** – гаризаларны карау һәм алга таба документларны конкурс комиссиясенә тапшыру өчен Министрлык тарафыннан төзелгән совет;

**чыгымнар планы** – конкурс комиссиясе раславына гариза бирүче тарафыннан тәкъдим ителгән гранттан файдалануның юнәлешләре буенча чыгымнарның статьялап эшләнгән сметасы;

**грант алучы** – Программада катнашучы дип тану өчен конкурс сайлавын узган һәм грант алуга шартнамә төзегән КФХ башлыгы.

1.2. Грант гаризасы конкурс комиссиясе тарафыннан расланган КФХ башлыгына бирелә.

1.3. Конкурс комиссиясе эшен оештыруны Министрлык башкара.

1.4. Грант чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алына торган мөлкәт, башкарыла торган эшләр атамалары буенча куелган хакның кимендә 40 процентын үз акчалары исәбеннән түләү йөкләмәсен алган КФХ башлыкларына бирелә.

Грант хисабына КФХ башлыгы тарафыннан сатып алынган мөлкәт грант алган көннән башлап 10 ел дәвамында сатылырга, бүләк ителергә, арендага тапшырылырга, башка затлар файдалануына бирелергә, алмаштырылырга яки пай, кертем рәвешендә кертелергә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төрле тартып алынырга тиеш түгел. Бу шарт гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукцияләрен эшкәртү предприятиеләрен үстерүгә грантлар бирү чараларында катнашучылар өчен җитди булып тора.

## 2. Грантлар бирү күләме һәм шартлары

2.1. Грантлар грант алучыларга техник-икътисадый нигезләүгә ярашлы рәвештә максатчан чыгымнарны финанслашу шартларында кире кайтарылмый торган итеп гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә бирелә.

2.2. Грантлар гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә чыгымнар планында билгеләнгән һәр чыгым статьясының 60 процентыннан артык булмаган күләмендә, ләкин бер гариза бирүчегә биш миллион сумнан артык булмаган күләмдә бирелә.

2.3. Грантлар проектка салынган куәтләр түбәндәгечә булганда бүлеп бирелә:

кимендә 24 баш сыеры була торган сөт фермаларына;

кимендә 50 баш мөгезле эре терлекле сугымга симертү фермаларына;

кимендә 20 ана дуңгызлы (200 дуңгызлы) дуңгыз фермаларына;

кимендә 100 баш ана сарыгы була торган сарыклар үрчетү фермаларына;

кимендә 50 баш савым кәҗәсенә;

кимендә 4000 баш бройлер, 4000 баш йомырка сала торган тавыклары яки 1000 баш каз яки 1500 үрдәк була торган кош фермаларына;

кимендә 20 мең баш бытбылдык була торган кош фермаларына;

кимендә 2000 баш була торган күркә үрчетү фермаларына;

кимендә 100 баш (50 бия) була торган ат фермаларына.

2.4. Грантлар тиешле елга һәм план чорына федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында законнарда Министрлык өчен бу максатларга каралган бюджет акчалары чикләрендә бирелә.

2.5. Конкурста катнашу өчен КФХ түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

а) КФХ башлыгы һәм әгъзалары булып туганнар булган һәм аларның шәхси катнашуына нигезләнгән җитештерү эшчәнлеген бергә башкаручы Россия Федерациясе гражданнары (кимендә ике) тора.

б) конкурска гариза бирү датасына КФХ эшчәнлеге срогы теркәлү датасыннан 12 айдан күбрәк;

в) КФХ дәүләт теркәве һәм аның җитештерү эшчәнлеген башкаруы бары тик Татарстан Республикасы муниципаль районы территориясендә, моңа Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясы нигезендә республика әһәмиятендәге шәһәрләр керми;

г) хуҗалык башлыгы һәм әгъзалары элек КФХ төзү һәм үстерүгә грантлар, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар алмаган я КФХ төзүгә һәм үстерүгә грантны, эш башлаучы фермерларның көнкүрешен җиһазлауга бер тапкыр бирелә торган ярдәмне, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантны тулысынча үзләштереп бетерү датасыннан кимендә өч ел үткән;

д) хуҗалык "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә микропредприятие критерийларына туры килә;

е) хуҗалык үзенең азык базасын яки башка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр белән уртак азык базасын төзү өчен шартларны күз алдында тота йә азык сатып алуга шартнамәләр (башлангыч шартнамәләр) төзү буенча тәкъдимнәр әзерли;

ж) хуҗалык Программада авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм куллану балансларын һәм бер генә тапкыр башкарыла торган гамәлләргә каршы чараларны исәпкә алып каралган терлекчелек эшчәнлегенең бер юнәлеше (бер тармагы) буенча бердән артык булмаган гаилә терлекчелек фермасын төзүне планлаштыра яисә бердән артык булмаган гаилә терлекчелек фермасын реконструкцияләргә планлаштыра;

хуҗалыкта терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча үз базасы булмаганда һәм (яисә) хуҗалык авыл хуҗалыгы кулланучылары кооперативы әгъзасы булып тормаганда, гаилә терлекчелек фермасын үстерү өчен авыл хуҗалыгы терлегенең хуҗалык тарафыннан планлаштырыла торган саны сөт яисә ит бирә торган ана башларның төп көтүе 100 баш мөгезле эре терлектән, 300 баш кәҗәдән (сарыктан) артып китмәскә тиеш;

з) хуҗалык башлыгы хуҗалык башлыгының бердәнбер эш урыны булган хуҗалыкның урнашу һәм теркәлү урыны буенча муниципаль берәмлектә даими яшәү урынында даими яши яки анда күчеп килергә вәгъдә бирә;

и) хуҗалык башлыгының терлекчелекнең Программада билгеләнгән эшчәнлек юнәлеше (тармагы) буенча югары продуктив терлеге һәм югары технологияле җиһазлары булган гаилә терлекчелек фермасын төзү һәм үстерү,

сатыла торган терлекчелек продукциясенең күләмен арттыру планы, үз бәясен чыгару срогы 8 елдан артмаган гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү нигезләве (алга таба – бизнес-план) була;

к) хуҗалык башлыгы, сатып алына торган мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең (алга таба – сатып алулар) исемнәрен, аларның исәбен, хакын, финанслау чыганакларын (грант акчалары, үз акчалары һәм заем акчалары) күрсәтеп, чыгымнар планын тапшыра;

л) хуҗалык башлыгы чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алуларның һәр исеме буенча хакның кимендә 40 процентын, шул исәптән сатып алуларның һәр исеме буенча хакның кимендә 10 процентын турыдан-туры үз акчалары исәбеннән түләргә йөкләмә ала;

м) хуҗалык башлыгы акчаларның хуҗалык башлыгы счетына күчкән көненнән алып 24 ай эчендә грантны кулланырга һәм грант хисабына фәкать гаилә терлекчелек фермасын үстерү һәм эшчәнлек башкару өчен сатып алына торган мөлкәттән файдаланырга йөкләмә ала;

н) хуҗалыкта кимендә өч даими эш урынын булдыру өчен шартлар тудырыла;

о) КФХ гаилә терлекчелек фермасын үстерүгә грант алганнан соң кимендә биш ел дәвамында эшчәнлек башкарырга йөкләмә ала;

п) гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү, аны үстерүне хуҗалык тәкъдим итә, элек дәүләт ярдәме акчаларын кулланып гамәлгә ашырылмаган;

р) КФХ башлыгы һәм әгъзалары Россия Федерациясе законнары нигезендә үзләренең персональ белешмәләрен тапшыруга һәм эшкәртүгә үз ризалыгын бирәләр;

с) барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салым һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләү вакыты узган бурычлары булмау;

т) хуҗалык башлыгы коммерциягә караган оешманың гамәлгә куючысы (катнашучысы) булып тормый, моңа үзе җитәкчелек иткән КФХ керми;

у) КФХ карата юкка чыгару яки банкротлык процедуралары уздырылырга тиеш түгел;

ф) КФХ башлыгы грантны номиналсыз исәп-хисап ясау юлы белән сарыф итәргә йөкләмә ала.

2.6. Грант чыгымнар планы нигезендә Грант алучы тарафыннан түбәндәгеләргә тотылырга мөмкин:

гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүнең проект документларын эшләүгә;

гаилә терлекчелек фермасын төзүгә, реконструкцияләүгә яки модернизацияләүгә;

терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча җитештерү объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә яки модернизацияләүгә;

гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча объектларны җиһазлар һәм техника белән җиһазлауга, шулай ук аларны монтажлауга;

авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга.

2.7. Грант КФХга бары тик бер генә тапкыр бирелергә мөмкин.

2.8. КФХ башлыгы бурычлары:

грант алганнан соң 5 ел дәвамында Министрлыкка квартал саен 1 нче кушымта нигезендә “Эшчәнлек турында белешмәләр” хисабын тапшыру;

чыгымнар планы нигезендә грант акчаларын һәм үз акчаларын тотканнан соң, 2 нче кушымтада каралган “Җыелма реестр”ны, акчаларны үз вакытында һәм максатка ярашлы рәвештә тотуын раслый торган хисап-финанс документларын (исәп-хисап счетыннан грант акчаларының йөрешен раслый торган банк өземтәсе, сату-алу шартнамәсе, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счет-фактуралар, фото һ.б.ш.) тапшыру. Хисап документлары Россия Федерациясе законнары нигезендә шундый документлар дип танылган раслау документларыннан гыйбарәт.

## 3. Программада катнашу өчен конкурс комиссиясенә тапшырыла торган документлар исемлеге

3.1. Программада катнашу өчен КФХ башлыклары түбәндәге документлар тапшыра:

3.1.1. Әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада каралган форма буенча гариза;

3.1.2. КФХ дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;

3.1.3. Гариза биргән көнгә кадәр иң күбе өч ай алдан Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә;

3.1.4. Россия Федерациясе гражданы – КФХ башлыгы һәм КФХ әгъзаларының паспортлары күчермәләре, аларның туганлыгын яки хосусиятен раслый торган документлар (туу турында таныклык, язылышу турында таныклык яки башка охшаш документлар);

3.1.5. Әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада каралган КФХ әгъзалары арасындагы килешү;

3.1.6. Дәүләт статистика күзәтүе органнарына № 2–фермер “Авыл хуҗалыгы культуралары уңышын җыю турында белешмәләр” һәм № 3–фермер “Терлекчелек продукциясен җитештерү һәм терлек башлары турында белешмәләр” формалары буенча соңгы хисап датасына хисаплар;

3.1.7. Югары продуктив терлеге һәм югары технологияле җиһазлары булган гаилә терлекчелек фермасын төзү һәм үстерү буенча сатыла торган терлекчелек продукциясе күләмен арттыруны күздә тоткан, үз бәясен чыгару срогы сигез елдан артмаган гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү буенча нигезләве булган, өстәмә рәвештә кимендә өч даими эш урынын булдыру өчен шартлар тудыру каралган бизнес-план, шулай ук грант хисабыннан финанслашу өчен күздә тотыла торган акчаларның, сатып алына торган мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең исемнәрен, аларның исәбен, хакын, финанслау чыганакларын күрсәтеп, кәгазьдә

һәм электрон чыганакта әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымтада каралган чыгымнар планы проекты;

3.1.8. Гариза бирүчедә чыгымнар планының кимендә 40%ы күләмендә үз һәм кредит (заем) акчалары булуны раслый торган документлар, аларның 30%ы субсидияләнмәгән кредитлар йә проектны гамәлгә ашыруга башкарылган үз кертемнәре һәм 10%ы үз акчалары булырга мөмкин.

Гариза бирүченең үз акчалары һәм кредит акчалары булуын раслый торган документлар:

кредит оешмасы счетыннан өземтә яки гариза бирүче счетларында акча булуны раслый торган башка документ;

күләме күрсәтелеп, кредит (заем) алу ихтималы турында кредитор (заем бирүче) тарафыннан бирелгән документ;

соралган акчаларны гариза бирүчегә бирү турында кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) күчермәләре;

гариза бирү датасына проект гамәлгә ашырылу стадиясендә булса, “Россия Федерациясендә бәйләү эшчәнлеге турында” 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән бәяләү эшчәнлеге стандартларына туры китереп бәйсез бәяләүче тарафыннан башкарылган мөлкәтне бәйләү турында хисап. 2010 елдан иртәрәк булмаган вакытта төзелә (реконструкцияләнә) башлап, төзелеп (реконструкцияләнеп) беткән яки кимендә 50% әзерлек стадиясендәге ферманың булуы раслана. Ферманы төзү (реконструкцияләү) буенча үз акчалары хисабына башкарылган эшләрнең хакы проект бәясенең 30%ыннан ким булмаска тиеш, моннан тыш кимендә 10%ы грант алганнан соң турыдан-туры акчалата түләнергә тиеш.

3.1.9. Гариза бирүче белешмәсе, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

а) КФХның “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә микропредприятие критерийларына туры килүен раслый торган уртача хезмәткәрләр саны турында белешмәләрне (узган календарь елда уртача хезмәткәрләр саны, гариза бирүченең гариза бирү вакытына хезмәткәрләре саны, шул исәптән, КФХ башлыгын да кертеп, КФХ әгъзалары саны);

б) “Бөлгенлек (банкротлык) турында” 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бетерү яки банкротка чыгару процедуралары КФХ кагылышлы уздырылмау турында белешмәләрне;

в) хуҗалык башлыгы һәм әгъзаларының элек крестьян (фермер) хуҗалыгын төзүгә һәм үстерүгә грантлар, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар алмавы турында белешмәләрне;

3.1.10. Җитештерү биналары, техника, җиһазлар, терлек әм кош башлары булу турында авыл җирлегеннән һәм муниципаль берәмлектән әлеге Нигезләмәгә 6 нчы кушымтада каралган белешмә;

3.1.11. Үз-үзен җайга сала торган оешмага (алга таба – СРО) проектлауга (төзүгә яки реконструкцияләүгә грант кулланылганда) рөхсәт күчермәләре беркетелгән гаилә терлекчелек фермаларының локаль сметалары һәм схема-

сызымнары (башкарылачак эшләр урыны фотосы, объект булган очракта – аның эчен һәм тышын төшергән фото) кушымта итеп бирелгән җыелма смета исәпләве;

3.1.12. Гаилә терлекчелек фермаларын төзүгә (реконструкцияләүгә) һәм (яисә) файдалануга кертүгә (төзүгә яки реконструкцияләүгә грант кулланылганда) рөхсәт;

3.1.13. Гариза бирү көненнән 30 көннән дә алдарак бирелмәгән барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салым һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләү вакыты узган бурычлары булмауны раслый торган салым органыннан белешмә;;

3.1.14. Әлеге Нигезләмәгә 7 нче кушымтада нигезендә персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

3.1.15. Әлеге Нигезләмәгә 8 нче кушымтада каралган форма буенча КФХ башлыгы анкетасы;

3.1.16. Законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән җир кишәрлегенә милекчелек хокукларын һәм (яисә) җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;

3.1.17. КФХ урнашу һәм теркәлү урыны буенча гариза бирүченең яшәү фактын раслый торган авыл (шәһәр) җирлеге белешмәсе;

3.1.18. КФХ башлыгының хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

3.1.19. Иминләштерелгән затның – КФХ башлыгының мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы хосусый счетыннан соңгы хисап датасына өземтә;

3.1.20. Социаль иминият фондына соңгы хисап датасына хисапның (Форма-4 ФСС) хисапны кабул итү турында фонд тамгасы куелган күчермәсе;

3.1.21. Пенсия иминият фондына соңгы хисап датасына хисапның (Форма РСВ-1 ПФР) хисапны кабул итү турында фонд тамгасы куелган күчермәсе.

3.2. Белешмәләрнең дөреслеге һәм тапшырылган документларның чын булуы өчен җаваплылык КФХ башлыгына йөкләнә. Конкурс комиссиясенә документлар әзерләү һәм тапшыру белән бәйле барлык чыгымнарны КФХ башлыклары түли.

Таныклау таләп ителгән һәм берничә биттән гыйбарәт документлар тапшырылганда, һәр бите таныклана. Документларның төп нөсхәләре проектны яклаганда конкурс комиссиясендәге күчермәләр белән чагыштырып карау өчен бирелә.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар КФХ башлыгы тарафыннан имзаланган, тегелгән, номерлар сугылган һәм КФХ башлыгы мөһере белән таныкланган булырга тиеш. Бетерүләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, вәкаләтле вәкил мөһере белән расланган һәм имзасы белән таныкланган (юридик затлар өчен) яки үз кулы белән таныкланган (КФХ башлыгы өчен) төзәтүләрдән тыш.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар конкурс сайлавын уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән вакыт эчендә һәм адрес буенча тапшырыла.

Грантлар бирү тәртибе һәм документларның формалары турында мәгълүмат “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – интернет) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми

сайтына http://agro.tatarstan.ru/, “Мәгълүмат-консультация хезмәте” бүлегенә, “Россия Федерациясе бюджеты катнашында гаилә фермаларына ярдәм” бүлекчәсенә урнаштырыла.

Гариза бирүче конкурс комиссиясенә (турыдан-туры әңгәмә вакытында) КФХны программаның потенциаль катнашучы буларак уңай бәя бирердәй, конкурс комиссиясенә йогынты ясардай түбәндәге документлар тапшырырга мөмкин:

а) муниципаль хакимият органнарынннан КФХ үсешен, аның җитештерү күрсәткечләре динамикасын, шулай ук булырга мөмкин социаль-икътисадый нәтиҗәне һәм грант бирүнең максатка ярашлы булуын күрсәтә торган тәкъдим хатлары;

б) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларга милекчелек хокукларын дәүләт теркәве турында таныклыкның күчермәсе, техник чара паспортының күчермәсе (милкендә техник чара булганда);

в) җитештерү биналары (шул исәптән төгәлләнмәгән төзелеш), авыл хуҗалыгы терлеге, техникасы һәм җиһазлары фотосы;

г) гариза биргән вакыттан әлеге Нигезләмәнең 2.5. һәм 3.1. пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры китереп эшләп бетерелгән документлар;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан мәкаләләр һәм башка документлар.

## 4. Гаризаларны кабул итү һәм теркәү

4.1. Грантлар бирү буенча конкурс сайлавында катнашуга гаризалар кабул ителә башлау турында белдерү интернет челтәрендә Министрлыкның http://agro.tatarstan.ru/ рәсми сайтына “Мәгълүмат-консультация хезмәте” бүлегенең “Россия Федерациясе бюджеты катнашында гаилә фермаларына ярдәм” бүлекчәсенә урнаштырыла.

Белдерүдә конкурс уздырылу урыны һәм вакыты, элемтәгә керү өчен телефоннар, Министрлык сайтының документларны тапшыру тәртибе һәм конкурс шартлары турында мәгълүмат алырга, норматив документлар белән танышырга мөмкин булган бүлекләре күрсәтелә.

4.2. Гаризалар кабул ителә башлау көне дип белдерү бастырылган көннән соң килә торган көн санала. Белдерүдә күрсәтелгән срок узганнан соң, КФХ башлыкларыннан гаризалар кабул ителми.

Алынган гаризалар һәм документларны теркәү гаризаларны теркәү журналына язылып баруына карап башкарыла, ул номерланган, тегелгән һәм конкурс комиссиясе секретаре имзасы һәм Министрлык мөһере белән беркетелгән булырга тиеш. Гаризаны теркәгәндә аңа керү номеры сугыла.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясе секретарена кәгазьдә тапшырыла, өстәмә буларак электрон рәвештә әлеге Нигезләмәнең 3.1.7. (бизнес-план), 3.1.11. (смета буенча локаль исәп-хисаплар һәм җитештерү бүлмәләренең, КФХ да булган техниканың, терлек белән кошларның фотодокументлары) һәм 3.1.15. (анкета) пунктчаларында күрсәтелгән

документлар тапшырыла. Конкурс комиссиясенә КФХ башлыгы тарафыннан бирелә торган барлык документларның исемнәре, номерлары һәм даталары, алардагы битләр саны ике нөсхәдә төзелә торган исемлеккә кертелә. Конкурс комиссиясе секретаре тапшырылган документларны аларга кушымта итеп бирелгән исемлек белән (әлеге Нигезләмәгә 9 нчы кушымта) чыгыштырып караганнан соң, алар КФХ мөһере белән таныклана торган конвертка салыналар. Конвертта шулай ук программаның исеме, проектка салынган куатнең юнәлеше, КФХ исеме, гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм адресы күрсәтелә. Исемлек бите конвертка салынмый. Документларны кабул иткәндә исемлек битенә документларның кабул ителүен раслый торган тамга салына, кабул итү датасы һәм теркәлү номеры күрсәтелә.Кабул ителү турында тамга салынган исемлек битенең бер нөсхәсе КФХ башлыгында кала, ә икенчесе документлар пакетына өстәп куела.

Гаризаны һәм документларны кабул иткәндә аларның тулылыгын һәм куелган таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү башкарылмый.

## 5. Конкурс комиссиясенең функцияләре һәм бурычлары

5.1. Конкурс комиссиясе үз эшчәнлеген законнарга, әлеге Нигезләмәгә таянып башкара һәм үз эшен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме инфраструктурасын тәшкил итә торган оешмалар, иҗтимагый оешмалар һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары белән үзара хезмәттәшлектә торып оештыра.

5.2. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грант алу өчен гариза бирүче тарафыннан тапшырылган конкурс документациясен үз вакытында, ачык һәм объектив карауны тәэмин итү;

проектларга аларның тулылыгын һәм дөреслеген, икътисадый нәтиҗәлелеген, Татарстан Республикасы икътисады өчен социаль әһәмиятле булуын һәм дәүләт ярдәме күрсәтүнең максатка ярашлы булуын билгеләү максатында экспертиза ясау;

конкурсның җиңүчеләрен һәм аларга бирелә торган грантларның күләмен билгеләү.

5.3. Конкурс комиссиясе Министрлык боерыгы белән кимендә 12 кешедән төзелә һәм конкурс комиссиясе рәисеннән, рәисе урынбасарыннан, секретареннан һәм әгъзаларыннан гыйбарәт була. Конкурс комиссиясе әгъзалары арасында дәүләт хезмәткәрләре саны иң күбе 50 процентны тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе рәисе:

конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аңа йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен җавап бирә;

конкурс комиссиясе әгъзалары арасында йөкләмәләр бүлә;

конкурс комиссиясе утырышларын алып баруны, утырышлар беркетмәләре әзерләнүне һәм конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыра.

5.4. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, конкурс комиссиясе утырышында рәис булмаган очракта, аның вазыйфаларын башкара.

5.5. Конкурс комиссиясе секретаре:

гаризалар кабул ителеп беткәннән соң биш эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышында каралырга тиешле гаризаларның тапшырылган документлары белән исемлеген төзи;

гаризалар кабул ителеп беткәннән соң биш эш көне эчендә документларны электрон рәвештә экспертлар советы каравына тапшыра;

конкурс комиссиясе утырышының көн тәртибе буенча материаллар әзерләүне оештыра, документлар әйләнешен һәм утырышларда конкурс комиссиясе әгъзаларының катнашуын, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен рәмиләштерүне тәэмин итә;

гаризалар кабул ителеп беткәннән соң 10 эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышын гариза бирүчеләрне турыдан-туры әңгәмәгә чакырып оештыра;

конкурс тәмамланганнан соң 30 эш көне эчендә барлык гаризаларны һәм документларны, шулай ук конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән барлык документларны, биш ел дәвамында саклау өчен, Министрлык архивына тапшыра.

5.6. Йөкләнгән вәкаләтләрне, консультацияләрне гамәлгә ашыру, тапшырылган документларга экспертиза ясау өчен конкурс комиссиясе экспертлар советын җәлеп итә. Экспертлар советы Министрлык боерыгы белән кимендә 12 кешедән төзелә һәм экспертлар советы рәисеннән, секретареннан һәм әгъзаларынанн гыйбарәт була.

Экспертлар советы:

конверларны ача һәм әлеге Нигезләмәдә каралган документларның булуын тикшерә;

КФХ башлыгының һәм аның тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

бәяләү ведомостенә кертеп, балларның исәбен саный һәм конкурс комиссиясе каравына тәкъдим итү характерындагы бәяләмә чыгара.

Экспертлар советы рәисе:

экспертлар советы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аңа йөкләнгән вазыйфаларның үз вакытында үтәлүе өчен җаваплы була;

экспертлар советы әгъзалары арасында йөкләмәләр бүлә.

Экспертлар советы рәисе булмаган очракта, аның вазыйфаларын экспертлар советы рәисе урынбасары башкара.

Экспертлар советы секретаре экспертлар советы утырышын һәм конкурс комиссиясе өчен экспертлар советы бәяләмәсен әзерләү эшен оештыра.

Экспертлар советы утырышы КФХ башлыкларының әлеге Программа буенча конкурска гаризаларын кабул итү тәгәлләнгән вакыттан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча уздырыла.

5.7. Конкурс комиссиясе гаризалар кабул итү тәгәлләнгән вакыттан 15 эш көненнән дә соңга калмыйча конкурс комиссиясе утырышын үткәрә, гариза бирүчеләр тарафыннан тапшырылган документларны, аларның туры килүе турында экспертлар советы тәкъдимнәрен карый, КФХ башлыкларына грантлар

бирү йә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән (алга таба – беркетмә) рәсмиләштерелә.

Турыдан-туры әңгәмә барышында конкурс комиссиясе әгъзасы гаризаларда бирелгән мәгълүматка һәм бирелгән сорауларга гариза бирүченең җавапларына нигезләнеп, тиешле карар кабул итә һәм, бирелә торган грантның күләмен күрсәтеп, һәр КФХ башлыгы буенча Тавыш бирү кәгазенә язма кертә.

5.8. Конкурс комиссиясе карары, конкурс комиссиясе составының яртысыннан артыгы булу шарты үтәлгәндә, тавышлар күпчелеге буенча кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Билгеләнгән критерийлар буенча баллар санын бертигез җыйган берничә дәгъва итүче булып, тиешле грант саны катнашучыларның санына караганда кимрәк булса, грант “Конкурска гаризалар теркәүнең 1 номерлы журналы”нда алданрак теркәлгән гариза хуҗасына бирелә.

Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан Тавыш бирү кәгазъләрендә чагылган карарларына нигезләнеп, секретарь конкурс бюллетенен төзи. Тавыш бирү кәгазъләре һәм конкурс бюллетене беркетмәгә өстәп куела.

Конкурс комиссиясе утырышлары аны уздыруга ихтыяҗ булган саен үткәрелә. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырышка рәис карары буенча чакырыла. Конкурс комиссиясе секретаре утырышка кадәр өч көн алдан гариза бирүчеләрнең электрон рәвештә тапшырылган, каравы планлаштырылган документларын һәм экспертлар советы бәяләмәсен, өйрәнү өчен, конкурс комиссиясе әгъзаларына җибәрә.

Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат интернет челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтына http: //agro.tatarstan.ru/, “Мәгълүмат-консультация хезмәте” бүлегендәге “Россия Федерациясе бюджеты катнашында гаилә фермаларына ярдәм” бүлекчәсенә конкурс комиссиясе карары кабул ителгән вакыттан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Конкурс комиссиясе утырышы анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашкан очракта үз хокукларын башкара ала.

5.9. Конкурс комиссиясе, экспертлар советы бәяләмәсенә һәм гариза бирүчеләр тарафыннан тапшырылган документларга ясалган анализга нигезләнеп, түбәндәге критерийларга карап, конкурс сайлавы җиңүчеләрен билгели:

| № п/п | **Критерий исеме** | **Күрсәткечләр** | **Баллар белән бәяләү** |
|---|---|---|---|
| 1 | Конкурс сайлавында катнашу өчен гариза бирү вакытына терлекләр һәм кошларның баш исәбе булу (шартлы баш саны)* | 5 алып 10 кадәр | 1 |
| | | 11 алып 30 кадәр | 3 |
| | | 31 күбрәк | 5 |
| 2 | Башкарыла торган эшчәнлекнең төрен күрсәтеп өстәмә эш урыннары булдыру | 4-5 урын | 1 |
| | | 6-9 урын | 3 |
| | | 10 һәм аннан күбрәк урын | 5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Инженерлык челтәрләренә - электр, су, юл, газ, җылылык, канализация – кирәкле тоташулар булу | ике һәм аннан күбрәк | 3 |
| | | бер | 1 |
| 4 | Конкурс сайлавында катнашу өчен гариза бирү вакытына гариза бирүченең милкендә авыл хуҗалыгы техникасы һәм җиһазлары булу (берәмлек) | 1 алып 3 кадәр | 1 |
| | | 3 алып 5 кадәр | 2 |
| | | 5 күбрәк | 3 |
| 5 | Проектны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләре булу** | милектә | 3 |
| | | арендада | 1 |
| 6 | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлеге мәйданы (гектар) | 5 алып 10 кадәр | 1 |
| | | 10,1 алып 50 кадәр | 3 |
| | | 50 күбрәк | 5 |
| 7 | Ферманың юнәлеше | мөгезле эре терлекне сөт өчен һәм симертү өчен ашату | 5 |
| | | атчылык, кошчылык | 3 |
| | | кәҗә үрчетү, сарык үрчетү, дуңгызчылык | 1 |
| 8 | Гариза бирүче эшчәнлегенә турыдан-туры мөнәсәбәте булган оешмалардан хуҗалык алып баруның уңай тәҗрибәсе булу турында мәгълүматны һәм грант алган очракта ферманы үстерү перспективаларына бәяне үз эченә алган тәкъдим рәвешендәге хатларның булуы | ике һәм аннан күбрәк | 2 |
| | | бер | 1 |
| 9 | **Бизнес-планга бәя бирү** | | |
| а) | проектның үз бәясен чыгару чоры | 5 елга кадәр | 3 |
| | | 7 елга кадәр | 1 |
| б) | авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативында катнашу яки үзенең эшкәртүен һәм әзер продукцияне сатуны оештыру. Гариза бирүченең соңгы елларда аларга эшкәртү һәм сату өчен тапшырылган продукция күләмнәре турында мәгълүмат бар | үз эшкәртүе һәм әзер продукцияне сату | 7 |
| | | авыл хуҗалыгы кооперативлары аркылы сату | 3 |
| | | читтәге эшкәртүчегә сату | 1 |
| в) | үз азык базасы булу | Үз азык базасы | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хисабына 50 процентка кадәр азык белән тәэмин ителү | |
| | | 100 процентка кадәр | 3 |
| г) | Гариза бирүче тарафыннан конкуренция мохитен һәм үзенең өстенлекләрен бәяләү | потенциаль конкурентларга характеристика бирелү (көчле һәм көчсез яклары, базардагы өлеше, тармакка йогынты ясау дәрәҗәсе һ.б.ш.) | 3 |
| | | җавап тулы түгел | 0 |
| д) | проект куәтенә чыкканннан соң җитештерүнең рентабельлеге | 10-20 процент | 1 |
| | | 21 процент һәм югарырак | 3 |
| 10 | Гариза бирүченең эшлеклелек сыйфатларын, һөнәри осталыгын, социаль һәм бюджет җаваплылыгын бәяләү (срокларын, мәҗбүри түләүләр күләмнәрен һәм хезмәт хакы түләү срокларын саулау), (әңгәмәдән соң куела) | | Максималь балл – 20 |

* 1 пунктта күрсәтелгән күрсәткечнең зурлыгын исәпләп чыгарганда терлек һәм кошларны шартлы баш исәбенә күчергәндә түбәндәге коэффициентлар кулланыла: мөгезле эре терлек (олы) һәм ат – 1,0; мөгезле эре терлек (яшь) – 0,6; дуңгызлар - 0,3; сарыклар һәм кәҗәләр - 0,1; кош - 0,02.

** Әгәр гариза бирүченең җир кишәрлекләре аның милкендә дә, шулай уртача күләме аренда да булган очракта “Проектны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләре булу” 5 пунктындагы баллар саны милектәге җирләр өлешеннән һәм арендадагы җирләр өлешеннән, җир кишәрлекләренең гомуми мәйданнына чыгып исәпләнә.

5.10. Бәя куела торган һәр проект буенча йомгак балл чыгарыла, ул әлеге Нигезләмәнең 5.8 пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча гариза бирүче балларының суммасы буларак билгеләнә. Баллар тегелгән документлар буенча гына санала, конкурс комиссиясе утырышында күрсәтелгән документлар баллар суммасына кушылмый. Җыярга мөмкин булган балларның иң күбе 70 була. Конкурс комиссиясе уңай карар чыгарсын өчен 30 балл җыярга кирәк.

5.11. Беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яки аның урынбасары, секретаре һәм утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана. Министрлык беркетмә имзаланганнан соң 5 көн эчендә конкурс сайлавы нәтиҗәләрен раслау турында боерык чыгара һәм Министрлыкның муниципаль районнардагы Авыл

хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә, конкурста катнашучыларга хәбәр итү өчен, кабул ителгән еонкурс комиссиясе карары турында хәбәр иткән хат юллый.

5.12. Конкурс комиссиясе, объектив сәбәпләр аркасында чыгымнар планы нигезендә грант акчаларын тотуга каршылык тудыра торган эшкуарлык эшчәнлеге шартлары үзгәргән йә гариза бирүче проектны гамәлгә ашырудан баш тарткан очракта, күрсәтелгән үзгәрешләрне килештерү һәм өстәмә утырыш уздыру турында карар кабул итә.

5.13. Әгәр конкурска бирелгән гаризаларның саны яки грант откан фермерларның саны финанслау бүленгән фермерлар санынннан кимрәк булса, Министрлык яңа конкурс игълан итә.

## 6. Грант бирү һәм аны кире кайтару тәртибе

6.1. КФХ башлыгына грант, грант бирү турында беркетмәгә һәм шартнамәгә нигезләнеп, Министрлык боергы нигезендә бирелә.

Гаризалары грант бирелүгә уңай бәяләмә алган КФХ башлыклары конкурс сайлавы нәтиҗәләре турында мәгълүмат алганнан соң биш эш көне эчендә Министрлыкка түбәндәге документлар тапшыра:

а) әлеге Нигезләмәгә 10 нчы кушымтада каралган форма буенча белешмә-хисапны;

б) конкурс комиссиясе раслаган юнәлешләре буенча әлеге Нигезләмәгә 11 нче кушымтада каралган чыгымнар планын;

в) әлеге Нигезләмәгә 12 нче кушымтада каралган форма буенча грант бирү турында шартнамәне.

6.2. Министрлык грант алу өчен тапшырылган документларны, аларның керүенә карап, махсус журналда терки, ул номерланган, тегелгән, Министрлык мөһере белән расланган булырга тиеш. Теркәү язмасында теркәү номеры, документларны кабул итү көне һәм конкурс комиссиясе нәтиҗәләре буенча грант суммасы күрсәтелергә тиеш.

6.3. Министрлык документларны теркәү көненнән соң биш эш көне эчендә кергән документларны тикшерә һәм грант алучы тарафыннан тапшырылган әлеге Нигезләмәнең 6.1. пунктында каралган белешмә-хисапны һәм шартнамәне имзалый.

6.4. Гариза бирүчегә грант бирүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

әлеге Нигезләмәнең 6.1. пунктында каралган документларның тулы пакеты тапшырылмаган булса;

әлеге Нигезләмәнең 6.1. пунктында каралган тапшырылган документларда күрсәтелгән белешмәләрнең, исәп-хисапларның факттагы белешмәләргә, исәп-хисапларга туры килмәве ачыкланса.

6.5. Министрлык, КФХ башлыкларының алар тарафыннан кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына грант күчерү өчен, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына түбәндәгеләрне тапшыра:

6.5.1. Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен раслау турында Министрлык боерыгын;

6.5.2. Әлеге Нигезләмәнең 6.1. пунктында күрсәтелгән әлеге Нигезләмәнең 6.3. пункты нигезендә имзаланган грант күләме исәп-хисабын һәм шартнамә күчермәсен.

6.6. Грантларның максатка ярашлы файдалануын тикшереп тору Министрлык тарафыннан башкарыла.

6.7. Грантны алучылар, әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә күрсәтелгән грант бирү шартларын бозган очракта, законнар нигезендә җаваплы булалар.

6.8. Грант бирү федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау лимитларын исәпкә алып башкарыла. Грант алуга конкурс сайлавын үткән гаризаларны канәгатьләндерү өчен быелгы елда бюджет акчалары җитәрлек булмаса, аларны финанслау әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә максималь баллар саны буенча чират тәртибендә гамәлгә ашырылачак.

Грантның максатка ярашлы рәвештә кулланылмавы һәм (яисә) грант алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу фактлары ачыкланса, бирелгән грант суммасы законнар нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

Нигезләмәгә 1 нче кушымта

Ешлык: (киләсе ярты елның 10 нчы числосына кадәр)

"КИЛЕШТЕРЕЛДЕ":
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
идарәсе башлыгы
__________________ /__________/

# Эшчәнлек турында белешмәләр

______ елга______________________ ТР муниципаль районының __________________ КФХ.
(Ф.И.О.)

“2015 - 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” программасы буенча ____________________ ______ баш .

**1.Җитештерү күрсәткечләре:**

| т/б № | Баш саны булу | | Җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе исеме | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме, тн | | Сату күләме, тн | | Алынган табыш, мең сум. | | Барлык чыгымнар, мең сум. | Рентабельлек, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Авыл хуҗалыгы терлегенең исеме | Саны, баш. | | Хисап чорында барлыгы | шул исәптән хисап датасына (кварталга) | хисап елында барлыгы | шул исәптән хисап датасына (кварталга) | Хисап елында барлыгы | шул исәптән хисап датасына (кварталга) | | |
| 1 | | | Сөт | | | | | | | | * |
| 2 | | | Ит | | | | | | | | * |
| 3 | | | һ.б.ш. | | | | | | | | * |
| 4 | | | | | | | | | | | * |
| 5 | | | | | | | | | | | * |
| Барлыгы | | | Барлыгы | * | * | * | * | | | | |

**2. Салым салу, хезмәткәрләр саны һәм аларның хезмәт хакы:**

| т/б № | Хуҗалык хезмәткәрләренең белгечлеге исеме | | Ф.И.А и. | Исәпләнгән хезмәт хакы, мең сум | | Салымнар, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Барлыгы, салымнар | шул исәптән | | | | |
| | | | | Хисап елында барлыгы | шул исәптән хисап датасына (кварталга) | | хезмәт хакыннан күчерелгән акча | Җир салымы | Мөлкәткә салым | Транспорт салымы | Бердәм авыл хуҗалыгы салымы |
| 1 | КФХ башлыгы | | | * | * | | | | | | |
| 2 | КФХ әгъзасы | | | | | | | | | | |
| 3 | Грант алганчы булган хезмәткәрләр саны - ____ кеше | | | | | | | | | | |
| 4 | Яңа эшкә алынган-нар | | | | | | | | | | |
| 5 | | | | | | | | | | | |
| 6 | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | | | | |

**3. Ферманы үстерүгә грант акчалары тотылуга бәя.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | җир кишәрлеге зурлыгы (га) : | милектә - | , арендада - |
| 2 | КФХ башлыгының субъектив бәяләве буенча, грант нәрсә эшләргә | | |
| | | | |
| 3 | Авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү һәм сату ничек җайга салынган? | | |
| | | | |
| 4 | КФХ да нинди социаль җаваплылык бар? | | |
| | | | |
| 5 | КФХның нинди проблемалары, сораулары бар? | | |
| | | | |
| 6 | КФХ ны үстерү | | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм: КФХ башлыгы____________ _____________ /Ф.И.А. и. имза/ Мөһер урыны

Нигезләмәгә 2 нче кушымта

"КИЛЕШТЕРЕЛДЕ":
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
идарәсе башлыгы
_____________ /______________/

Матди-техник кыйммәтләр, хезмәт күрсәтүләр, терлек, техника сатып алуга грант акчаларын тоту исәбенең
**җыелма реестры**

КФХ башлыгы_______________________________________

ТР _______________муниципаль районының _______________ авыл җирлеге ____________ торышына

Грант суммасы ___________мең сум

Ферма юнәлеше ____________________ _________баш

| №№ т/б | Түләүне (түләү йөкләмәсен) раслый торган документ исеме | Документ датасы | Документ номеры | Кайдан (сатучы исеме) | Сатып алынган товар - матди кыйммәтләрнең (терлек, төзелеш материаллары, техника, хезмәт күрсәтүләр һ.б.) исеме | Үлчәү берәмлеге | Саны | Бер берәмлек бәясе, сум | Сумма, сум | Финанслау чыганагы (грант, җәлеп ителгән яисә үз акчалары) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. | | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | | | |
| 4. | | | | | | | | | | |
| 5. | | | | | | | | | | |
| 6. | | | | | | | | | | |
| | Барлыгы: | Х | Х | Х | Х | Х | | Х | | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм: КФХ башлыгы ____________________ /Ф.И.А.и./ ____________________/ Имза/

Мөһер урыны

12.03.2015 елның 37/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгы белән
расланган Нигезләмәгә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары -
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министры
М.Г.Әхмәтовка
___________________________________________
___________________________________________
___________________________________________
(КФХ башлыгы Ф.И.А.и., яшәү урыны адресы)

**“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашучыларны конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен**
**гариза**

Мин, ______________________________________________________________
________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең тулы рәсми исеме)
мине “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында (алга таба – Программа) катнашучыларны конкурс нигезендә сайлап алуда катнашучылар составына кертүегезне сорыйм.

Моның белән мин түбәндәгеләрне раслыйм:

1. КФХ башлыгы булып эшләү урыны минем хезмәт эшчәнлегенең бердәнбер урыны булып тора.

2. Программада катнашу шартлары белән таныштым һәм килешәм.

Минем хуҗалык Программада катнашучы дип танылган очракта, йөкләмә алам:

а) чыгымнар планында күрсәтелгән чыгымнарның һәр статьясы хакының кимендә 40 процентын түләргә;

б) крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген грант алган көннән башлап кимендә биш ел дәвамында башкарырга;

в) соралган вакыт эчендә хисаплар тапшырырга;

г) грантны үзләштергән көннән башлап, КФХ башлыгы һәм әгъзаларыннан тыш, өстәмә рәвештә кимендә өч даими эш урынын булдыру өчен шартлар тудырырга.

Тапшырылган документлардагы яки аларның күчермәләрендәге барлык мәгълүмат дөрес, грант бирелүгә документлар караучы катнашучы затларның алар белән танышуына каршы түгел.

____________ /______________/ «____» _________, 20____ел
(имза) (Ф.И.А.и.)

Мөһер урыны

12.03.2015 елның 37/2-14 номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә
4 нче кушымта

«___» ____________ 20____ел
Россия, Татарстан Республикасы,
_________________ муниципаль районы
«________________________________КФХ»
фермер хуҗалыгы әгъзалары җыелышында
"РАСЛАНДЫ"

« ________________________________________ КФХ»

**фермер хуҗалыгын төзү турында**
**КИЛЕШҮ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Без, - ____________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
«Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «____________________________________КФХ» фермер хуҗалыгын төзү турында карар кабул иттек.

1.2. «________________________________КФХ» крестьян-фермер хуҗалыгы
(исеме)
(алга таба - фермер хуҗалыгы) эшкуарлык эшчәнлеген законнар һәм әлеге килешү нигезендә юридик зат төзеп тә һәм аны төземичә дә башкара.

1.3. Фермер хуҗалыгының үз мөһере бар.

1.4. Фермер хуҗалыгының аерымланган мөлкәте бар, ул кредит оешмаларында исәп-хисап счетларын ачу хокукына ия, үз исеменнән мөлкәти һәм шәхси мөлкәти булмаган хокук алырга һәм йөкләмәләр булдыру, гомуми юрисдикция, арбитраж һәм третейский судларда дәгъвачы һәм җавапчы булу хокукына ия.

1.5. Фермер хуҗалыгының урнашу урыны (аның дәүләт теркәве урыны) адресы: __________________________________________________ .
Фермер хуҗалыгы Татарстан Республикасы ___________________________ муниципаль районының __________________________ авыл җирлегендә урнашкан, ә җир кишәрлеге, җир кишәрлеген һәм кадастр планын сайлау актында каралганча, Татарстан Республикасы __________________________ муниципаль районының __________________________ авыл җирлегендә урнашкан.

1.6. Факттагы хуҗалык адресы: ____________________________________ .

## 2. Фермер хуҗалыгына идарә итү һәм аның эшчәнлеге

2.1. Фермер хуҗалыгы башлыгы итеп ____________________________________
____________________________________________________________________таныйрга.
(фамилиясе, исеме, атасы исеме)

2.2. Фермер хуҗалыгы башлыгы вәкаләтләре:

- фермер хуҗалыгы эшчәнлеген оештыра;
- ышаныч кәгазеннән башка фермер хуҗалыгы исеменнән эш йөртә, шул исәптән аның мәнфәгатьләрен җиткерә һәм алып-сатулар ясый;
- ышаныч кәгазе бирә;
- фермер хуҗалыгына эшкә хезмәткәрләр кабул итә һәм аларны эштән җибәрә;
- фермер хуҗалыгының исәбен һәм хисаплылыгын алып баруны оештыра;
- ул эш йөртә торган фермер хуҗалыгы мәнфәгатьләрендәге гамәлләрне ихтыярый һәм уйлап башкара, ләкин фермер хуҗалыгының һәм аның әгъзаларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кыса торган гамәлләр кылырга хокуксыз;
- фермер хуҗалыгына кагылышлы башка вәкаләтләрне законнар нигезендә башкара.

2.3. Фермер хуҗалыгы башлыгын алмаштыру «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла һәм аның фермер хуҗалыгында әгъза булып торуы туктатылуга китерми.

2.4. Җир кишәрлегенә милекчелек (хуҗа булу) хокукына нигезләнгән фермер хуҗалыгы үзенең эшчәнлек юнәлешен, структурасын һәм җитештерү күләмнәрен, иү ихтыяҗларыннан чыгып, мөстәкыйль билгели.

Фермер хуҗалыгы законнар белән тыелмаган теләсә нинди эшчәнлек төре белән шөгыльләнә ала, тик бу вакытта үзе җитештергән авыл хуҗалыгы һәм терлекчелек продукциясен җитештерү, эшкәртү, транспортлау, саклау һәм сату эшчәнлекнең әйдәүче төре буларак сакланып калырга тиеш.

2.4.1. Фермер хуҗалыгының үзе җитештергән продукция белән эш итү һәм аны үз карамагында сату, җитештерелә торган продукциягә бәяне мөстәкыйль кую хокукы бар.

## 3. Фермер хуҗалыгы әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары, фермер хуҗалыгы әгъзасы итеп кабул ителү һәм әгъзалыктан чыгу

3.1. Фермер хуҗалыгы әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

а) җир кишәрлегендә мөстәкыйль хуҗалык итәргә;

б) фермер хуҗалыгы эшчәнлеге өчен кирәкле торак, производство, көнкүреш һәм башка төзелмәләрне һәм корылмаларны аларның проектларын билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри килештереп һәм төзелешкә рөхсәт алып төзергә;

в) алар тарафыннан утыртылган авыл хуҗалыгы культураларына һәм утыртмаларына, алынган авыл хуҗалыгы һәм башка продукциягә һәм аларны сатудан кергән керемгә;

г) билгеләнгән тәртиптә сугару, киптерү, культура-техника һәм башка мелиорация эшләрен башкарырга, табигатьне саклау таләпләренә туры китереп, буалар һәм башка сулыклар төзергә;

д) әлеге килешүдә законнар нигезендә җайга салынмаган мәсьәләләрне фермер хуҗалыгы әгъзалары җыелышында фикер алышу юлы белән хәл итәргә, карар фермер хуҗалыгы әгъзаларының гади тавыш күпчелеге белән кабул ителә;

е) фермер хуҗалыгы әгъзалыгыннан уйланылган чыгу көненә кадәр ике атнадан соңга калмыйча үз нияте турында хәбәр итеп чыгарга;

ж) фермер хуҗалыгыннан чыккан очракта, фермер хуҗалыгы мөлкәтенә гомуми милекчелек хокукындагы өлешләренә тиң акчалата компенсациягә.

3.2. Фермер хуҗалыгы әгъзалары түбәндәгеләргә бурычлы:

а) максатчан билгеләнешенә ярашлы рәвештә җир кишәрлегеннән нәтиҗәле файдаланырга, җир уңдырышлылыгын арттырырга;

б) фермер хуҗалыгы мөлкәтеннән эксплуатацияләү кагыйдәләренә һәм кулланмаларына ярашлы рәвештә файдаланырга, аның сакланышын тәэмин итәргә;

в) фермер хуҗалыгы башлыгы күрсәтмәләрен, фермер хуҗалыгы җыелышы карарларын, эчке тәртип кагыйдәләрен үтәргә.

3.3. Фермер хуҗалыгы фермер хуҗалыгы әгъзалары булып тормаган затларны эшкә алырга хокуклы. Хезмәткәрләрне эшкә алу, хезмәт өчен түләү шартлары һәм башка шартлар хезмәт килешүендә (шартнамәсендә) билгеләнә.

3.4. Әлеге килешүне имзалаган затлар фермер хуҗалыгы әгъзалары була.

3.5. Фермер хуҗалыгына яңа әгъзалар кабул итү гражданның язма гаризасы нигезендә фермер хуҗалыгы әгъзаларының уртак ризалыгы белән башкарыла.

3.6. Фермер хуҗалыгындагы әгъзалык фермер хуҗалыгы әгъзалыгыннан чыкканда яки фермер хуҗалыгы әгъзасының вафат булуы очрагында туктатыла.

3.7. Фермер хуҗалыгы әгъзасының фермер хуҗалыгыннан чыгуы аның язма гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.

## 4. Фермер хуҗалыгы мөлкәте

4.1. Фермер хуҗалыгы мөлкәте түбәндәгеләрдән гыйбарәт: җир кишәрлеге, үсемлекләр, торак, хуҗалык каралтылары, корылмалары, файда китерә торган һәм эшче терлек, кош, авыл хуҗалыгы техникасы һәм җиһазлары, транспорт чаралары, инвентарь һәм фермер хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка мөлкәт.

4.2. Фермер хуҗалыгы мөлкәтен булдыру чыганаклары:

фермер хуҗалыгы әгъзаларының акчалары һәм матди чаралары;

продукция сатудан, акчага, шулай ук натуралата эшләр башкарудан, хезмәтләр күрсәтүдән, ярдәмче кәсепләрдән, төзелештән, консультация ярдәменнән һәм хезмәт эшчәнлегенең башка төрләреннән алынган керемнәр;

кыйммәтле кәгазьләрдән, банк кредитларыннан һәм башка кредитлардан алынган керемнәр;

бюджет дотацияләре һәм предприятиеләрнең, оешмаларның һәм гражданнарның кире кайтарылмый торган хәйрия кертемнәре, иганәләре;

законнар белән тыелмаган чыганаклар.

4.3. Мөлкәткә хуҗа булу, аннан файдалану һәм аның белән эш йөртү:

4.3.1. Фермер хуҗалыгы мөлкәте аның әгъзаларына уртак милекчелек хокукында карый;

4.3.2. Фермер хуҗалыгы мөлкәтеннән файдалану аның әгъзалары тарафыннан уртак килешү буенча башкарыла, мөлкәт белән эш итү буенча алыш-бирешләр фермер хуҗалыгы башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм, кирәк булган очракта, фермер хуҗалыгы әгъзалары арасындагы шартнамә белән рәсмиләштерелә.

4.3.3. Фермер хуҗалыгы әгъзаларының берсе аның составыннан чыкканда җир кишәрлеге һәм производство чаралары бүленми. Мөлкәтне бүлешү һәм компенсация түләү тәртибе фермер хуҗалыгының барлык әгъзаларының уртак килешүе буенча, ә ул булмаса – суд тәртибендә билгеләнә. Бу вакытта акчалата компенсация түләү срогы фермер хуҗалыгыннан чыгу турындагы гаризаны фермер хуҗалыгы әгъзаларына биргән вакыттан бер елдан артык буларга тиеш түгел;

4.3.4. Фермер хуҗалыгы предприятиеләрдән, оешмалардан һәм гражданнардан мөлкәт сатып алырга, арендага яки вакытлыча файдалануга алырга хокуклы;

4.3.5. Фермер хуҗалыгы мөлкәте законнар нигезендә ихтыярый иминләштерелә;

4.3.6. Фермер хуҗалыгы әгъзалыгыннан чыккан граждан, аның фермер хуҗалыгы әгъзалыгыннан чыгуына кадәр фермер хуҗалыгы эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча фермер хуҗалыгы мөлкәтендәге үз өлеше бәясе чикләрендә чыкканнан соң ике ел дәвамында субсидиар җаваплы була;

4.3.7. Фермер хуҗалыгы аннан әгъзалары чыгуга бәйле рәвештә беткәндә фермер хуҗалыгы мөлкәте законнар нигезендә аның әгъзалары арасында бүленергә тиеш;

4.3.8. Фермер хуҗалыгы мөлкәтен мираска алу законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Фермер хуҗалыгы эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган уңышларны, продукцияне һәм керемнәрне бүлү тәртибе турында

5.1. Фермер хуҗалыгы эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган уңышлар, продукция һәм керемнәр әгъзалары арасында һәр әгъзаның шәхси өлешен исәпкә алып бүленә.

5.2. Хезмәтләреннән файдалану турында шартнамә төзегән фермер хуҗалыгы хезмәткәрләренең (әгъзалары түгел) хезмәте өчен түләү агымдагы чыгымнар составына кертелә һәм беренче чиратта башкарыла, ул фермер хуҗалыгы эше нәтиҗәләренә бәйле түгел, моңа шартнамәдә календарь елда фермер хуҗалыгы кеременнән процентлар түләү каралган очраклар керми.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Фермер хуҗалыгы үз эшчәнлеген түбәндәге очракларда туктата:

фермер хуҗалыгы әгъзалары бертавыштан карар кылган очракта;

фермер хуҗалыгы әгъзаларыннан берәү дә яки фермер хуҗалыгы эшчәнлеген

дәвам итәргә теләгән варислары калмаган очракта;

фермер хуҗалыгының бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү очрагында;

фермер хуҗалыгы мөлкәте базасында җитештерү (авыл хуҗалыгы) кооперативын яки хуҗалык ширкәтен төзү очрагында;

суд карары нигезендә.

6.2. Фермер хуҗалыгы эшчәнлеген туктатуга бәйле барлыкка килгән бәхәсләр законнар нигезендә хәл ителә.

## 7. Килешүдә катнашучыларның реквизитлары һәм имзалары

«____________________________________КФХ» фермер хуҗалыгын төзү турында килешүдә катнашучылар:

1. _______________________________, 19_____елның___________ туган, туу урыны ______________________, __________________ районы ______________,
теркәлү адресы:
ТР,______________________________________________________________________
____________________________________, _______________ ур., ___й. _____фат.,
тору адресы:
ТР,______________________________________________________________________
____________________________________, _______________ ур., ___й. ____фат.,,
паспорт сериясе ________ № ______________, 20___елның __________
_____________________________ бирелгән, бүлекчә коды __________ .

2. _______________________________, 19_____елның___________ туган, туу урыны ______________________, __________________ районы ______________,
теркәлү адресы:
ТР,______________________________________________________________________
____________________________________, _______________ ур., ___й. _____фат.,
тору адресы:
ТР,______________________________________________________________________
____________________________________, _______________ ур., ___й. ____фат.,,
паспорт сериясе ________ № ______________, 20___елның __________
_____________________________ бирелгән, бүлекчә коды __________ .

12.03.2015 елның 37/2-11 номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгы белән расланган Нигезләмәгә
5 нче кушымта

# Бизнес-планның тәкъдим ителгән формасы

## Титул бите:

Күрсәтелә:

крестьян (фермер) хуҗалыгының (алга таба – КФХ), районның исеме, баш исәбен күрсәтеп, гаилә терлекчелек фермаларының юнәлеше, төзелү датасы, КФХ адресы һәм КФХ элемтә телефоны.

## Резюме

Проект турында кыскача мәгълүмат бирелә:
